**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **23.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Әлкәй авыл җирлеге составына керүче
Кызыл Сукачы авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Әлкәй авыл җирлеге Кызыл Сукачы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Кызыл Сукачы авылының юлларын кардан чистарту;

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлкәй авыл җирлеге Башлыгы С.З.Зиннурова